Reviews

Бәяләмә һәм күзәтүләр

Рецензии и обзоры

# ON THE "TATAR-TURKISH DICTIONARY" BY M. ONER (ÖNER MUSTAFA. KAZAN-TATAR TÜRKÇESI SÜZLÜĞÜ/ MUSTAFA ÖNER. - GENIŞLETILMIŞ 2. BSK. ANKARA: TÜRK DIL KURUMU, 2015. 604 S.)

**Ozkan Oztekten (Özkan Öztekten),**
Ege University,
Bornovo, Izmir, 34100, Turkey,
ozkan.oztekten@ege.edu.tr.

**Elvira Nikolaevna Denmukhammetova,**
Kazan Federal University,
18 Kremlevskaya Str., Kazan, 420008, Russia,
elvir25@mail.ru.

The review analyzes the "Tatar–Turkish Dictionary" (Kazan-Tatar Türkçesi Süzlüğü) published by the Turkic Linguistic Institute (Türk Dil Kurumu) in 2015. It was compiled by Mustafa Oner (Öner Mustafa), professor and translator of Turkish Ege University, known for his works in the Turkic world. The review considers the structure of the dictionary and the features of its entries. Despite the fact that the author is an ethnic Turk, he is fluent in the Tatar language and knows folklore and literature of the Tatar people. He makes great contributions to Turkology by studying the vocabulary and grammar of the Tatar language in comparison with other Turkic languages and by researching the language of such prominent representatives of the Tatar people as G.Iskhaki, G.Tukay, Derdmend, F.Amirhan et al. In the reviewed work the author provides many examples from Tatar proverbs, sayings riddles and omens, and also gives samples of written Tatar speech from classical Tatar literature and the works of contemporary authors. The authors of the review note that this dictionary is of great importance for the strengthening of intercultural relations. It will be a useful educational aid and an indispensable tool for translation, as it contains lexical units of the modern Tatar language, examples of dialectic words and obsolete vocabulary. Reviewers underline the importance of the dictionary for the entire Turkic world.

**Key words**: bilingual dictionaries, Turkish and Tatar languages, Turkology, intercultural relations, dictionary structure, Mustafa Oner.

From ancient times the Tatars have been a well-educated and knowledgeable nation, and it is the reason for their rich lexical heritage. The diversity, changing tendencies and usage peculiarities of the Tatar vocabulary are reflected and engraved in manuscripts and in later publications. All this had a

great influence on different types of dictionaries subsequently compiled: at first there were translation dictionaries, later on etymological and translation dictionaries, then terminological, encyclopedic and illustrated dictionaries came into existence. In recent years electronic dictionaries have been widely used, and they are slowly replacing printed ones. Being easy to use, they quickly became popular.

Bilingual and multilingual lexicographic works are considered to be the most important treasures of any language as they are extremely useful for studying and teaching language and translation. There are a lot of these dictionaries in the Tatar language as well, among them are Tatar-Russian, Russian-Tatar, Arabic-Tatar and English-Russian dictionaries. The history of the first ones dates back to the handwritten dictionaries of the $15^{th}$-$17^{th}$ centuries; nonetheless, they serve as a source of historical data concerning social, economic, cultural and other relations between the Tatars and Russians. It has been a long time since the compilation of the first dictionaries, hence, the methods of their compilation, content and linguistic domains have changed and many new lexicographic examples from other languages have been included. As such, different nations have had the possibility of developing their relationships, and people have more opportunities to communicate, collaborate and learn from each other. The pleasant thing is that not only do the Tatars compile bilingual dictionaries of Tatar but other nations do it as well in order to learn Tatar, thus fixing the relationship between Tatar and their own language.

The Tatar-Turkish and Turkish-Tatar dictionaries were compiled for the same reasons. Turkey and Tatarstan developed social, economic and scientific relations at the end of the $20^{th}$ century, and in 1997-1998, the "Tatar-Turkish Dictionary" (by F. Ganiev, R. Akhmetyanov and Kh. Achykgyoz) and the "Turkish-Tatar dictionary" (by R. Akhmetyanov, R. Mokhammatdinov, F. Nurieva and F. Ganiev) were compiled and helped Tatars learn the Turkish language. These dictionaries serve as an important source for studying the similar and peculiar words of the languages and as irreplaceable data for translators and interpreters.

Later in 2009 in Ankara, Turkey, Mustafa Oner published the "Tatar-Turkish Dictionary" (*Kazan-Tatar Türkçesi Süzlüğü*). One thousand copies of the 358-page dictionary were published in the "Turek tel kurumy" Publishing House. It included 8127 dictionary entries. This dictionary proves the strength and potential of the relationship between two countries and two nations.

The "Tatar-Turkish Dictionary" was republished in 2015 on the initiative of the "Turek tel kurumy" Publishing House and now consists of 604 pages. (Öner Mustafa. Kazan-Tatar Türkçesi süzlüğü/ Mustafa Öner /– genişletilmiş 2. Bsk. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2015. 604 s.). It includes 12,320 dictionary entries with examples from the modern Tatar language. The editors of the dictionary are the outstanding professors Ülkü Çelik Şavk and Emine Görsoy Naskali and its reviewers are Çörer Çölsevin and Hülya Kasapoğlu Çengel.

The dictionary is one of numerous scholastic works by Mustafa Oner dedicated to Tatar language studies. Despite being a Turk, the author nonetheless has a good command of the Tatar language, literature and folklore. He has been the head of the Literature Department of Izmir Ege University for decades, where his research mainly focuses on studying ancient and modern Turkic languages, their grammar and lexicology. He is the author of "Comparative vocabulary of the Tatar and Turkish languages", "Gabdulla Tukai and Turkish literature", "Outstanding turkologist-altaist Uzbek Baichura", "Ataturk and Turkish dialects", "Tatar poem's structure", "Orkhon inscriptions", "Zero morpheme in Crimean Tatar language", and "The Tatar language: grammar of Turkic dialects," etc. He is one of the scholars promoting the Tatar language in the Turkic community and across the globe.

In the introduction ("Sunuş") to the dictionary, Mustafa Oner proves his knowledge of Tatar vocabulary heritage. In his lexicographic work he introduces the Turkish readers to the vocabulary used by such classic Tatar writers and poets as Gabdulla Tukai, Shaekhzada Babich, Gayaz Iskhaki, Khadi Taktash, Musa Djalil, Sibgat Khakim, Khasan Tufan, Ibrakhim Salakhov, Garif Akhunov, Ayaz Gyilazhev, Mukhammat Makhdiev, Rkail Zaidulla, Mirgaziyan Unys, Zhaudat Suleimanov, and Rinat Muhammadiev. The author completes the entries with examples from classic Tatar literature and various proverbs, sayings and riddles, thus, giving the Turkish reader rich information about the Tatar language, literature, culture and folklore. For instance, aldan-Önce, evvel. Aldan kilgen urın öçĕn, soñdan kilgen tamaқ özĕn. "Önce gelen yer için, sonra gelen yemek için" – Mekal.; batır 1. Kahraman, cesur. 2. Güreşte herkesi yenen baş pehlivan. batır yöreklĕ Cesur yürekli. Batır bĕr ülgençe, қurқaқ öç üle. "Kahraman bir ölesiye,

korkak üç ölür." – Mekal. Batır yavda, tĕlçen davda bĕlĕnĕr. "Kahraman akında, dilbaz tartışmada bilinir." – Mekal. Suğış bĕtkeç batır kübeyĕr. "Savaş bitine kahraman çoğalır." – Mekal.; laf or – Boş boş konuşmak, çene çalmak. Diyüv periy başın özem dip ġayret bĕlen laf orıp mataşķanda, cĕgĕt aynıp ölgĕrgen. "Dev peri başını koparacağım deyip gayretle çene çalıp uğraşırken yiğit ayılıverdi." – Turay Batır; nadan 1. Cahil, okuma yazma bilmez. 2. Bir işten haberi olmayan, kendi işini iyi bilmeyen. Bĕtme nadan, tuġ yañadan / Meġ'rifetlĕ anadan! "Yetişme nadan, doğ yeniden / Bilgili anadan." – Remiyev.; sinђron – Senkron, eşzamanlı. Ķaysı ĸoştır, isĕmĕñ bĕlen / Siña ĸıçĸıra kĕbĕk; / Urmandağı herbĕr çeçek / Sinĕ yuĸsına kĕbĕk... "Hangi kuşsa, isminle / Sana bağırıyor gibi; / Ormandaki herbir çiçek / Seni yoksunur gibi..." – Tufan, etc.

M. Oner also includes examples from literary works by modern Tatar writers, such as Robert Minnulin, Rkail Zaidulla, Ravil Faizullin, Razil Valiev, Zhaudat Suleiman, Garai Rakhim, and Marsel Galiev, etc. Oner was glad that he had been able to find most of these works in the electronic book catalogue Tatknigafond (www.tatknigafond.ru).

Lexical entries were compiled according to 19th century traditions of dictionary compilation: verbs are listed in the imperative form and the literary forms are in line with dialect and colloquial forms. Apart from showing strong traditions, it gives the learners of the Tatar language information about the Tatar nation and its quotidian philosophy and helps to evoke learners' interest in the language.

The "Tatar-Turkish Dictionary" consists of an introduction (Sunuş), references (Genel Kaynaklar), source lists (Örnek Taranan Kaynaklar), the Tatar alphabet in Latin and 604 pages of dictionary entries.

The dictionary contains lexical entries actively used in literature and everyday speech. This includes primarily Turkic-Tatar words (i.e. *agach* (a tree), *chabyshu* (running), *yshanych* (trust), *kapkach* (a lid), etc.). It also comprises widely used Arabic and Farsi words (i.e. *gyibara* (a phrase), *gomuman* (general), *layek* (deserving), *milli* (national), *nadan* (ignorant), etc.) and Russian words or European borrowings that came into the language through Russian (i.e. *million, admiral, abstract, kvadrat* (square), *lira, liberal, norma* (norm), and *simphoniya* (symphony), etc.). The author also includes archaic words that are rarely used in current speech. For example, taliġ – *талиг* 1. Yaratiliє, tabiat, huy. 2. Talih, baht. Taliġa Ebedo baht, talih, *rizvay* – Rezil, risva; risvay it – Rezil etmek, etc. All of these words help to introduce Tatar history or historical vocabulary that is widely used in folklore and historical literature.

The dictionary was created not only as a scientific work; its practical purpose was taken into consideration as well. As mentioned above, it includes definitions of modern words along with dialect forms and colloquialisms; the fact that Tatar verbs are given in the infinitive or gerund form as in traditional dictionaries proves its practical purpose. This method helps beginners use the dictionary. In addition, the recurrent, imperative and joint mood forms of the verb are of great help. For instance, **irĕş** – 1. Erişmek, ulaşmak. 2. Haber duyulmak. 3. Maksadına ulaşmak; **irĕşĕlmeslĕk** – Erişilmezlik, gerçekleştirilemezlik; **irĕştĕr** – (I) 1. Ulaştırmak, yetiştirmek. 2. Gerçekleştirmek. 3. Düçar etmek, karşılaştırmak; **irĕştĕr** – (II) Takılmak, sataşmak, musallat olmak.

In conclusion, the outstanding turkologist Mostafa Oner's "Tatar-Turkish Dictionary" (1915) has become one of the ultimate sources for people learning Tatar and translating from Tatar into Turkish and from Turkish into Tatar. Just like other bilingual dictionaries, it truly reflects and preserves the international relationship between the two nations.

# М.ӨНӘРНЕҢ «ТАТАРЧА-ТӨРЕКЧӘ СҮЗЛЕГЕ» ТУРЫНДА (ÖNER MUSTAFA. KAZAN-TATAR TÜRKÇESI SÜZLÜĞÜ/ MUSTAFA ÖNER. - GENIŞLETILMIŞ 2. BSK. ANKARA: TÜRK DIL KURUMU, 2015. 604 S.)

**Өзкан Өзтәктән (Özkan Öztekten),**
Эгей университеты,
Төркия, 34100, Измир ш., Борново,
ozkan.oztekten@ege.edu.tr.

**Эльвира Николай кызы Денмөхәммәтова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
elvir25@mail.ru.

Бәяләмәдә төрки тел белемендә танылган галим, Төркиянең Эгей университеты профессоры, тәрҗемәче Мостафа Өнәрнең 2015 елда «Төрк тел курумы» тарафыннан нәшер ителгән «Татарча-төрекчә сүзлеге» (Öner Mustafa. Kazan-Tatar Türkçesi Süzlüğü) анализлана, аның төзелеше тасвирлана, сүзлек маддәләренең бирелешендәге үзенчәлекле моментлар күрсәтелә. Татар телен, фольклорын, әдәбиятын камил белүе белән аерылып торган, күп фәнни хезмәтләрендә татар теле лексикасын, грамматикасын башка төрки телләр белән чагыштырып тикшергән, Г.Тукай, Г.Исхакый, Дәрдмәнд, Ф.Әмирхан кебек күренекле татар әдипләренең телен өйрәнүгә үзеннән зур өлеш керткән бу галим әлеге хезмәттә дә күп санлы мәкаль һәм әйтем, табышмаклар, сынамышлар, классик әдәбияттан һәм хәзерге татар шагыйрьләре һәм язучыларының әсәрләреннән үрнәкләр тәкъдим итә.

Бәяләмә авторлары сүзлекнең мәдәниятара багланышларны ныгытуда әһәмияте зурлыгын ассызыклыйлар, тел өйрәнүчеләр һәм тәрҗемәчеләр өчен файдалы һәм кызыклы икәнлеген күрсәтәләр. Мостафа Өнәрнең бу сүзлеге төрки дөньяда әһәмиятле хезмәт буларак бәяләнә.

**Төп төшенчәләр**: икетелле сүзлекләр, төрек һәм татар телләре, төрки тел белеме, мәдәниятара багланышлар, сүзлек төзелеше, Мостафа Өнәр.

Татарлар борынгыдан аң-белемле, укымышлы халык булган, шунлыктан алар элек-электән килгән бай сүзлек мирасына ия. Татар теленең сүзлек байлыгы, үсеш-үзгәреш тенденцияләре, кулланылыш үзенчәлекләре башта кульязма, соңрак – басма хезмәтләрдә теркәлеп калган. Бу исә алга таба төзелә торган сүзлекләрнең төрләренә дә йогынты ясаган: башта тәрҗемәи сүзлекләр генә булса, соңрак аңлатмалы, берничә тел сүзлекләре барлыкка килгән, тора-бара аларга терминологик, энциклопедик, иллюстрацияле һ.б. төрләре өстәлгән. Соңгы елларда бу исемлекне электрон сүзлекләр дә тулыландырды һәм басма хезмәтләрне әкренләп алыштыра башлады. Гамәли яктан уңайлы булулары сәбәпле, алар бик тиз арада актив кулланылышка керде.

Тел өйрәтү һәм өйрәнү, тәрҗемә эше башкару өчен сүзлекләр кирәк булу сәбәпле, икетелле яисә күптелле тәрҗемәи лексикографик хезмәтләр теләсә кайсы телнең иң мөһим хәзинәләреннән санала. Мондый сүзлекләргә бай булган татар телендә дә татарча-русча, русча-татарча, гарәпчә-татарча, инглизчә-русча һ.б. ларны атарга була. Беренчеләренең тарихы XV-XVII гасырлардагы кульязма сүзлекләргә барып тоташса да, хәзерге көндә алар татарларның рус халкы һәм ике арада булган төрле икътисади, иҗтимагый, мәдәни һ.б. багланышларны чагылдыра торган тарихи чыганаклар ролен үтиләр. Беренче тәрҗемәи сүзлекләр төзелгәннән соң, күп вакытлар үткән, шунлыктан аларның төзелеше, кулланылу максатыннан чыгып эчтәлеге, телләр ареалы да үзгәргән, башка күп кенә телләр белән арадаш лексикографик үрнәкләр барлыкка килгән, димәк, халыклар белән элемтәләр төрле характердагы багланышлар торган саен күбрәк булдырылган, кешеләргә аралашу, тәҗрибә уртаклашу, гыйбрәт алу мөмкинлекләре арткан. Шунысы сөенечле: татар теленең мондый икетелле сүзлекләрен татарлар гына төземиләр, ә телне өйрәнү максаты белән, башка милләтләр дә үз телләре белән татар теле арасындагы бәйләнешләрне сүзлекләргә теркиләр.

Татарча-төрекчә һәм төрекчә-татарча сүзлекләр төзелү дә шул сәбәпләргә бәйле. XX гасыр ахырында Төркия белән Татарстан арасында икътисади, мәдәни, фәнни багланышлар артканнан соң, 1997-1998 елларда «Татарча-төрекчә сүзлек» (Төзүчеләре. Ф.Ганиев, Р.Әхмәтьянов, Х.Ачыкгөз) һәм «Төрекчә-татарча сүзлек»ләр (Төзүчеләре Р.Әхмәтьянов, Р.Мөхәммәтдинов, Ф.Нуриева, Ф.Ганиев) дөнья күрде һәм алар татарларга төрек телен үзләштерүдә зур ярдәм итте. Әлеге сүзлекләр бүгенге көнгә кадәр татар һәм төрек телләре арсындагы уртак лексиканы барлау, махсус лексик берәмлекләрне билгеләү, грамматик чаралар белән танышу өчен кирәкле әсбап ролен үти, шул ук вакытта тәрҗемә эшендә алыштыргысыз вазифа башкара.

Бераз соңрак 2009 елда Татарстаннан читтә – Төркиянең Анкара шәһәрендә Мостафа Өнәрнең дә «Татарча-төрекчә сүзлеге» (Kazan-Tatar Türkçesi Süzlüğü) басылып чыга. Әлеге сүзлек «Төрек тел курумы» нәшриятында 1000 нөсхәдә 358 битлек саллы хезмәт буларак дөнья күрә. Анда 8127 сүзлек маддәсе теркәлгән. Бу сүзлек ике ил, ике халык арасындагы мөнәсәбәтләр ныклыгының һәм дәвамлылыгының бер дәлиле булып тора.

Мостафа Өнәрнең «Татарча-төрекчә сүзлеге», тагын да тулыландырылып, 604 бит күләмендә «Төрек тел курумы» тарафыннан 2015 елда кабат басылды (Öner Mustafa. Kazan-Tatar Türkçesi süzlüğü / Mustafa Öner / – genişletilmiş 2. Bsk. Ankara: Türk Dil Kurumu, 2015. 604 s.). Хезмәт хәзерге татар телен яктырткан мисал-үрнәкләр белән дәлилләнгән 12320 сүзлек маддәсен тәшкил итә. Әлеге басманың мөхәррирләре мөхтәрәм профессорлар Үлкү Чәлик Шавк (Ülkü Çelik Şavk) һәм Әминә Гөрсой Наскали (Emine Görsoy Naskali), рецензентлары Җөрер Җөлсевин (Çörer Çölsevin) һәм Һулья Касапуглы Җәнгел (Hülya Kasapoğlu Çengel).

Сүзлек – Мостафа Өнәрнең татар телен өйрәнү юнәлешендә башкарган күпсанлы фәнни хезмәтләренең берсе. Автор, төрек булуга карамастан, татар телен камил белүе, татар әдәбияты һәм фольклорыннан яхшы хәбәрдар булуы белән аерылып тора. Ул дистә еллар дәвамында Измир шәһәрендәге Эгей университетында әдәбият бүлеген җитәкли, хәзерге һәм борынгы төрки телләрнең грамматикасын, лексикасын өйрәнү аның гыйльми эшчәнлегенең төп юнәлеше булып тора. Ул – «Татар һәм төрек телләренең чагыштырма лексикасы», «Габдулла Тукай һәм төрек әдәбияты», «Күренекле тюрколог-алтаист Үзбәк Байчура», «Ататөрек һәм төрек диалектлары», «Татар шигыре төзелеше», «Орхон язма истәлекләре», «Кырым татарлары телендә нуль морфема», «Татар теле: төрки диалектлар грамматикасы» һ.б. фәнни хезмәтләр авторы, төрки генә түгел, гомумән, дөньяга татар телен танытучы һәм пропагандалаучы галимнәрнең берсе.

Мостафа Өнәр сүзлегенең кереш («Sunuş») мәкаләсендә татар халкының элекке сүзлек мирасы белән таныш булуын бәян итә. Лексикографик хезмәтендә Габдулла Тукай, Шәехзадә Бабич, Гаяз Исхакый, Һади Такташ, Муса Җәлил, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Ибраһим Сәләхов, Гариф Ахунов, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев кебек классик әдипләр әсәрләрендә кулланылган лексика, Ркаил Зәйдулла, Миргазиян Юныс, Җәүдәт Сөләйманов, Ринат Мөхәммәдиев һ.б. татар язучылары һәм шагыйрьләре иҗатында чагылган татар теле белән төрек укучысын таныштыруны максат итеп куюын белдерә. Сүзлеккә тупланган хәзерге тел берәмлекләре классик әдәбияттан алынган мисаллар белән дәлилләнә, мәкаль һәм табышмак үрнәкләрен китереп, автор төрекләргә татар теле, аның әдәбияты, мәдәнияте һәм халык авыз иҗаты үрнәкләре турында бай мәгълүмат бирә. Мәсәлән: aldan – Önce, evvel. Aldan kilgen urın öçĕn, soñdan kilgen tamaķ özĕn. «Önce gelen yer için, sonra gelen yemek için» – Mekal; batır 1. Kahraman, cesur. 2. Güreşte herkesi yenen baş pehlivan. batır yöreklĕ Cesur yürekli. Batır bĕr ülgençe, ķurķaķ öç üle. «Kahraman bir ölesiye, korkak üç ölür» – Mekal. Batır yavda, tĕlçen davda bĕlĕnĕr. «Kahraman akında, dilbaz tartışmada bilinir» – Mekal. Suğış bĕtkeç batır kübeyĕr. «Savaş bitine kahraman çoğalır» – Mekal; laf or – Boş boş konuşmak, çene çalmak. Diyüv periy başın özem dip ġayret bĕlen laf orıp mataşķanda, cĕgĕt aynıp ölgĕrgen. «Dev peri başını koparacağım deyip gayretle çene çalıp uğraşırken yiğit ayılıverdi» – Turay Batır; nadan 1. Cahil, okuma yazma bilmez. 2. Bir işten haberi olmayan, kendi işini iyi bilmeyen. Bĕtme nadan, tuġ yañadan / Meġ'rifetlĕ anadan! «Yetişme nadan, doğ yeniden / Bilgili anadan» – Remiyev; sinhron – Senkron, eşzamanlı. Ķaysı ķoştır, isĕmĕñ bĕlen / Siña ķıçķıra kĕbĕk; / Urmandağı herbĕr çeçek / Sinĕ yuķsına kĕbĕk... «Hangi kuşsa, isminle / Sana bağırıyor gibi; / Ormandaki herbir çiçek / Seni yoksunur gibi...» – Tufan.h.б.

М.Өнәр хезмәтендә хәзерге татар әдәбиятында актив иҗат иткән Роберт Миңнуллин, Ркаил Зәйдулла, Равил Фәйзуллин, Рәзил Вәлиев, Җәүдәт Сөләйман, Гәрәй Рәхим, Марсель Галиев һ.б. ларның әсәрләреннән алынган мисалларга да зур урын бирелә. Ул аларның күбесен Таткнигофонддагы электрон китаплар каталогыннан (www/ tatknigafond.ru) алуын һәм мондый система булдырылуга куанычын белдерә.

Сүзлек лексемалар XIX гасыр сүзлек төзү традицияләре нигезендә теркәлгән: фигыльләр боерык фигыль формасында бирелә, әдәби тел нормалары белән янәшә, диалекталь, гади сөйләм сүзләре дә урын ала. Бу традицияләрнең ныклыгын күрсәтүдән тыш, тел өйрәнүчеләргә татар милләте, аның яшәеш-көнкүреше фәлсәфәсе турында бай мәгълүмат бирә, тел белән кызыксындыру вазифасын үти.

«Татарча-төрекчә сүзлек»нең төзелеше кереш мәкаләдән (Sunuş), файдаланылган әдәбияттан (Genel Kaynaklar), чыганаклар исемлегеннән (Örnek Taranan Kaynaklar), латиницада бирелгән татар алфавитыннан һәм 604 битлек сүзлектән гыйбарәт.

Хезмәттә язучылар телендә, язмаларында һәм хәзерге татар сөйләмендә актив кулланылышта булган лексик берәмлекләр тупланган. Алар арасында зур күпчелекне төрки-татар сүзләре тәшкил итә (мәсәлән, *агач, чабышу, ышаныч, капкач* һ.б.). Шулай ук телдә еш кулланыла торган гарәп һәм фарсы берәмлекләре (мәсәлән, *гыйбарә, гомумән, лаек, милли, надан* һ.б.) һәм рус сүзләре, рус теле аша кереп, хәзерге татар телендә кулланылышта йөри торган европа алынмалары да (мәсәлән, *миллион, адмирал, абстракт, квадрат, лира, либерал, норма, симфония* һ.б.) теркәлгән. Автор хәзерге вакытта активлыгын югалта барып, искергән сүз, архаизм тамгасы белән йөри торган берәмлекләрне дә сүзлегенә урнаштыра. Мәсәлән, *taliġ* – талиг 1. Yaratilig, tabiat, huy. 2. Talih, baht. Taliġa Ebedo baht, talih, rizvay – рисвай Rezil, risva; risvay it – Rezil etmek. һ.б. Бу – төрекләрне татар халкы тарихы, дөресрәге, тарихи лексикасы белән таныштыру өчен дә эшләнә, чөнки алар халык авыз иҗаты үрнәкләрендә һәм тарихи әсәрләрдә еш кулланыла.

Сүзлек фәнни хезмәт буларак кына түгел, ә гамәли максатларны да күздә тотып эшләнгән. Анда сүзләрнең, алда әйтелгәнчә, хәзерге телдә актив кулланыла торган барлык мәгънәләре, диалекталь сүзләр, кайбер очракта гади сөйләм формалары да урын алган; татар фигыльләрен гадәти сүзлекләрдәгечә инфинитив яки исем фигыль формасында тәкъдим итмәү безнең фикеребезне дәлилли. Бу юл телне әле камил белмәгән кешегә дә сүзлектән кирәкле форманы табуны җиңелләштерә. Шулай ук фигыльләрне кайтым, йөкләтү, уртаклык юнәлешләрендә бирү дә, мәгънә төсмерләрен ачыклау өчен тәрҗемә итүчегә уңайлык тудыра. Мәсәлән, **irĕş** – 1. Erişmek, ulaşmak. 2. Haber duyulmak. 3. Maksadına ulaşmak; **irĕşĕlmeslĕk** – Erişilmezlik, gerçekleştirilemezlik; **irĕştĕr** – (I) 1. Ulaştırmak, yetiştirmek. 2. Gerçekleştirmek. 3. Düçar etmek, karşılaştırmak; **irĕştĕr** – (II) Takılmak, sataşmak, musallat olmak.

Шул рәвешле күренекле тюрколог Мостафа Өнәрнең «Татарча-төрекчә сүзлеге» (2015) төрекләргә татар телен өйрәнүдә, татарчадан төрекчәгә һәм төрекчәдән татарчага тәрҗемә эшләре башкарганда, алыштыргысыз ярдәмче булып тора. Бу хезмәт тә, башка икетелле сүзлекләр кебек үк, чын мәгънәсендә, мәдәниятара бәйләнешләр көзгесе һәм сакчысы ролен үти.

# О СЛОВАРЕ М.ОНЕР «ТАТАРСКО-ТУРЕЦКИЙ СЛОВАРЬ» (ÖNER MUSTAFA. KAZAN-TATAR TÜRKÇESI SÜZLÜĞÜ/ MUSTAFA ÖNER. – GENIŞLETILMIŞ 2. BSK. ANKARA: TÜRK DIL KURUMU, 2015. 604 S.)

**Озкан Озтектен (Özkan Ötekten),**
Эгейский университет,
Турция, 34100, г. Измир, Борново,
ozkan.oztekten@ege.edu.tr.

**Эльвира Николаевна Денмухаметова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
elvir25@mail.ru.

В рецензии анализируется издание известного в тюркском мире своими трудами ученого, профессора Эгейского университета Турции, переводчика Мустафы Онера «Татарско-турецкий словарь» (Öner Mustafa. Kazan-Tatar Türkçesi süzlüğü), изданный Тюркским лингвистическим институтом в 2015 году, рассматривается структура словаря, указываются особенности строения словарных статей. Несмотря на то что автор является по национальности турком, он хорошо владеет татарским языком, знает фольклор, литературу татарского народа; изучая лексику, грамматику татарского языка в сравнительно-сопоставительном плане с другими тюркскими языками и занимаясь исследованиями языка таких видных представителей татарского народа, как Г.Исхаки, Г.Тукай, Дэрдменд, Ф.Амирхан и др., вносит большой вклад в тюркологию. В рецензируемой работе автором приводится множество примеров из татарских пословиц и поговорок, загадок и примет, представлены образцы письменной татарской речи как из классической татарской литературы, так и произведений современных авторов.

Создание данного словаря оценивается как весьма важное событие, способствующее укреплению межкультурных отношений. Он будет полезным пособием при обучении языку, незаменимым инструментом в переводческой работе, ведь в нем нашли отражение лексические единицы современного татарского языка, даны примеры диалектальных слов, устаревшей лексики. Словарь, по мнению рецензентов, будет иметь огромное значение для всего тюркского мира.

**Ключевые слова**: двуязычные словари, турецкий и татарский языки, тюркология, межкультурные отношения, структура словаря, Мустафа Онер.